| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**01.09.2020** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1612** |

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү уку программаларын үзләштерүче укучыларның 01.09.2020 елдан бушлай кайнар ризык белән туклануын оештыру турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, баланслы туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатыннан, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучыларның, күрсәтелгән мәгариф оешмаларында шундый белем алучы укучыларның 100 процент колачлауны тәэмин итеп,Татарстан Республикасында укучыларның бушлай кайнар ризык белән туклануын оештыру чаралары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары , «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 24 августындагы 728 номерлы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен 1.09.2020 елдан һәр уку көненә 51,85 сумга бушлай кайнар аш белән тәэмин итүне (туклануны) оештырырга.

2. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен уку чорында кайнар аш белән тәэмин итүне оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге

начальнигына әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин